Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының
Шәле авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлегенең ТатЦИК ис. торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

3 декабрь, 2021 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлегенең ТатЦИК ис. торак пункты гражданнарының 2021 елның 3 декабрендәге җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр ачыкланды:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 147 (йөз кырык җиде).

- халык җыены эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 81 (сиксән бер).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 79 (җитмеш тугыз).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 2 (ике).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2022 елда ТатЦИК исемендәге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, 80 яшькә җиткән гражданнарны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Шәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Әхмәтҗанов